Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге Советы Карары

«14» май 2021 ел                                                  № 30

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 15 декаберендәге 82 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

«Территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү турында" 30.12.2020 ел, № 494-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 декабрендәге 82 номерлы карары нигезендә расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы карарына 1 нче номерлы кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълуматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге башлыгы                                   А.Х.Кашшапов

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге Советының
2021 елның «14» май № 30 номерлы карарына
1 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 15 декаберендәге 82 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

Кышлау авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 декабрендәге 82 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**12 статьяның 3 абзацын түбәндәге эчтәлекле сүзләр белән тулыландырырга:**

« җирлекнең генераль планына, шәһәр округының Генераль планына үзгәрешләр әзерләү очракларыннан тыш, территорияне комплекслы үстерү турында Карар кабул ителү белән бәйле җәмәгать тыңлаулары яисә гавами тыңлаулар, аңа карата территорияне комплекслы үстерү турында Карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин».